
# Гаяз Исхакый(1878—1954)

Гумарова Энже 8«М»

# Гаяз Исхакый.





- Гаяз Исхакый (Мөхәммәтгаяз Исхакый Гыйлаҗетдин улы)– XX гасырның беренче яртысында татар, гомумән, төрки халыкларның киләчәге өчен эзлекле көрәш алып барган, шуны яшәвенең иң олы максаты итеп куйган милләт улларының иң күренеклесе. Шулай ук ул атаклы хикәяче, романчы, драматург, публицист, журналист, милли сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, татар әдәбияты классигы. Яңа чор татар әдәбиятына проза һәм драматургиядә зур өлеш керткән әдип.

# Гаяз Исхакый.

- Казан губернасы Чистай өязенә кергән әлеге авылның күпләргә билгеле зыялылар гаиләсендә туа ул. Замандашлары әйтүенчә, әтисе Гыйләҗетдин « Чистай тарафларында гыйлеме белән шөһрәт тапкан » мулла, ә әнисе Камәрия ул якларда шулай ук аң-белеме һәм азатлык идеялары белән танылган Морат мулла улларының берсе – Мөслимвәли хәзрәт кызы була



# Историко-мемориальный и этнографический музей Г. Исхаки



# Гаяз Исхакый.



- Унике яшендә аны Чистайдагы мәдрәсәгә бирәләр. Ләкин укыту тиешле булмаганга, өч елдан Гаяз Казандагы Күл буе мәдрәсәсенә килә. Аны биредә күренекле мәгърифәтче Һади Максуди укыта. 1897 елда, мәдрәсәне тәмамлагач, аны Әмирхановлар мәдрәсәсенә хәлфә итеп чакыралар, ә һ.Максуди монда мөдәррис булып күчә. 1898 елда Г.Исхакый Казан Татар укытучылар мәктәбенә укырга керә, аны 1902 елда тәмамлый.

# Гаяз Искахый.


- Әдәбиятка Гаяз шактый иртә килә. «Тәгаллемдә сәгадәт» исемле беренче әсәрен 17 яшендә яза. 1902 елда «Ике йөз елдан соң инкыйраз » исемле хыялый-публицистик повестен төгәлли. 1905 елгы революциягә кадәр үк инде ул дистәгә якын хикәя һәм повесть, ике пьеса һәм «Теләнче кызы» исемле романының беренче кисәген тәмамлый һәм күбесен дөньяга чыгара. ул 30 роман,драма һәм әсәрләр яза. Аның «Тәмуг», «Яшәүме соң бу » , «Мулла бабай », « Солдат», дигән әсәрләре аеруча абруй казана
- 1904 елны Казанга килеп, революцион хәрәкәткә кушылып китә. «Таң йолдызы» исемле газета чыгара башлый.



# Гаяз Исхакый.

- Гаяз Исхакый, хөкүмәткә каршы җинаятьтә гаепләнеп, 1906 елда кулга алына һәм Чистай төрмәсенә ябыла. Шунда «Зиндан» исемле автобиографик повестен яза. Аннары Архангельск губернасына сөргенгә җибәрелә. Шушы авыр шартларда ул «Солдат» повестен, «Теләнче кызы» романының икенче кисәген, берничә пьеса яза. Романовлар династиясенең 300 еллыгы уңае белән игълан ителгән амнистия нигезендә 1913 елда азат ителә.

- Гаяз Исхакый 1917 елның 22 ноябрендә Уфада Милли мәҗлестә катнаша. Ләкин ул милли мәсьәләнең хәл ителү рәвешен, гомумән, Совет властен кабул итә алмый һәм Ватаныннан китәргә мәҗбүр була.




# Гаяз Исхакый.

- Октябрьдә инкыйлаб булу милли мәсьәләне хәл итүне кыенлаштыра. Г.Исхакый 1919 елда чит илгә китәргә мәҗбүр була. Башта Кытайда, аннары Франциядә, Германиядә, Польшада яши. Икенче дөнья сугышы башлангач Төркиягә килә. Чит илләрдә яшәгәндә дә төпле газета-журналлар чыгара, әдәби әсәрләр иҗат итә.
- 1928—1939 елларда Берлинда яшәп, «Яңа милли юл» исемле журнал чыгара. 1935 елда Кытайда чыга башлаган «Милли байрак» газетасы шулай ук Г. Исхакый тырышлыгы белән дөньяга килә.
- Сталинизм чоры башлану белән Исхакый шәхес культын, аның өере урнаштырган режимны матбугат аша рәхимсез утка тота.

# Гаяз Исхакый.




Гаяз Исхакый 1954 елның 22 июлендә Әнкарада вафат була. Истанбулның Әдернәкапы зиратында җирләнә.